**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.07.2024 Казан шәһәре № 386

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2022 елның 22 ноябреннән «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибен раслау турында» 538 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2022 елның 22 ноябреннән « Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибен раслау турында» 538 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ маддәсендәге 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февраленнән «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февраленнән «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары турында һәм Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 178 нче карары нигезендә;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан күрсәтелгән боерык белән расланган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

3 – 8 абзацларда «2019-2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 – 13 абзацларда «2014 – 2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыру.»;

5 пунктта:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирүнең максаты булып чаралар үткәрү булган очракта чаралар программасын; әгәр субсидия учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга бирелә икән, түләүләр алучы физик затларның саны һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүматны;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга бюджет чараларын бирү кирәклеген нигезләүне, субсидия суммасын исәпләүне-нигезләүне дә кертеп, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) алдан сметаны үз эченә алган аңлатма язуын;»;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Документлар учреждение тарафыннан, бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасыннан файдаланып, электрон рәвештә тапшырылган очракта, алар учреждение җитәкчесе яисә учреждение җитәкчесе вазифаларын вакытлыча башкаручы тарафыннан электрон рәвештә имзаланырга тиеш.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Дәүләт программасының ярдәмче программаларын гамәлгә ашыру кысаларында субсидия күләме тиешле финанс елына һәм планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәләре белән билгеләнә.»;

9 пунктта:

беренче абзацта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирүнең максаты (субсидия дәүләт программаларының ярдәмче программаларын гамәлгә ашыру кысаларында бирелгән очракта, дәүләт программасының ярдәмче программасы атамасын күрсәтеп);

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидияләрне бирү максатлары белән бәйле рәвештә бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

чаралар үткәрүгә субсидия бирелгән очракта уздырылган чаралар саны (кимендә бер чара);

учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга бирелгән субсидия исәбенә кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә).

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү вакыты – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Гамәлгә куючы килешүдә каралган субсидияләрне күчерү графигы нигезендә учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетларына тулы күләмдә субсидияләр күчерә.».

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Учреждение гамәлгә куючыга ел саен хисап елыннан соң килә торган елның беренче 15 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә түбәндәге хисапларны тапшыра:

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән форма буенча хисап;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә (контроль нокталар) ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап.

Гамәлгә куючы килешүдә өстәмә хисап формалары һәм бирү вакытлары билгеләргә хокуклы.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гамәлгә куючы тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүгә һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга (контроль ноктасы) мониторинг уздырыла.»;

15 пунктның беренче абзацында «тапшырмау» сүзен «вакытында һәм дөрес тапшырмау» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибенең 1 нче, 2 нче кушымталарын әлеге боерыкка кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

Тәртипкә түбәндәге редакциядәге 3 нче кушымтаны өстәргә (теркәлә).

2. Әлеге боерык, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган әлеге боерыкның 1 пунктындагы 35, 36 абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазифаларын башкаручы Х.Х.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибенә
1 нче кушымта

20____ ел өчен___________________ ФИНАНС БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛЫП СУБСИДИЯ ТОРГАН ЧЫГЫМНАР ТУРЫНДА ХИСАП

Гамәлгә куючы атамасы ______________________________________________________
Учреждение атамасы ______________________________________________________
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| Субсидия | | Агымдагы финанс елы башына калган субсидия | | Кертемнәр | | | Түләүләр | | Курс аермасы | Хисап вакыт аралыгы азагына калган субсидия | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атамасы | БК буенча код | Барлыгы | Шулардан кулланырга рөхсәт ителгәне | Барлыгы, шул исәптән | Татарстан Республикасы бюджетыннан | узган еллар дебитор бурычыннан кире кайтарылган | барлыгы | Шулардан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылган | | Барлыгы | шул исәптән: | |
| | | | | | | | | | | | шул ук максатларга юллау таләп ителә | кире кайтарылырга тиеш |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче
(вазифаи зат) _____________ ___________ ____________________________
(вазифа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибенә
2 нче кушымта

Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында

20__ елның 1_______ торышы буенча хисап Дата

Җыелма реестр буенча учреждение атамасы _________________________

Җыелма реестр буенча гамәлгә куючы атамасы _______________________

БК буенча дәүләт программасы атамасы _______________________

Документ төре _______________________

(беренчел - "0", тәгаенләнгән - "1", "2", "3", "...")

Ешлыгы: айлык, квартал саен, еллык

Үлчәү берәмлеге: сум. ОКЕИ буенча

| КОДЛАР |
|---|
| |
| |
| |
| |
| |

1. Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү максатларында кабул ителгән күрсәткечләргә ирешү һәм йөкләмәләр турында мәгълүмат,

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидияләр бирү нәтиҗәләре | Үлчәү берәмлеге | | Юл коды | Планлы күрсәткечләр | | Килешү тарафыннан каралган субсидия күләме | Чынлыкта ирешелгән күрсәткечләр | | | | | | Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү максатында кабул ителгән йөкләмәләр күләме | | Финанс белән тәэмин итүнең кулланылмаган күләме (9 гр.- 16 гр.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | хисап көненә | | планлы күрсәткечтән тайпылыш | | тайпылышның сәбәбе | | | | |
| атамасы | БК буенча код | | атамасы | ОКЕИ буенча код | | килешү төзегәннән көннән башлап | шуларның агымдагы финанс елы башыннан | | килешү төзегән көннән башлап | шуларның агымдагы финанс елы башыннан | абсолют санннарда (7 гр. – 10 гр.) | процентларда (12 гр./ 7 гр. х 100%) | код | атамасы | йөкләмәләр | акчалата йөкләмәләр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | Барлыгы: | | | | | | | Барлыгы: | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _______________ _____________ ________________________________
(вазифа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Башкаручы ________________ _________________________________ _____________________
(вазифа) (фамилия, инициаллары) (телефон)

"___" ______________ 20___ ел

2. Сведения о принятии отчета о достижении значений результатов предоставления субсидии

| Күрсәткеч атамасы | Федераль бюджет бюджет классификациясе буенча код | КОСГУ | Сумма | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Килешү төзегән көннән башлап | шуларның агымдагы финанс елы башыннан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Нәтиҗәләргә ирешү өчен юлланган субсидияләр күләме | | | | |
| | | | | |
| Ихтыяҗы расланмаган субсидияләр күләме | | | | |
| | | | | |
| Бюджетка кире кайтарылырга тиешле субсидияләр күләме | | | | |
| Бюджетка күчерелергә тиешле штраф түләүләре (пенялар) күләме | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _______________ _____________ ________________________________
(вазифа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Башкаручы _______________ _____________________________ __________________

(вазифа) (фамилия, инициаллары) (телефон)

"___" ____________ 20___ ел

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибенә
3 нче кушымта

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында мәгълүмат (контроль нокталар)

20__ елның «__» ______ карата

| | | | КОДЛАР |
|---|---|---|---|
| | | Дата | |
| | | Җыелма реестр буенча | |
| Алучы атамасы | ______ | ИНН | |
| Татарстан Республикасы бюджеты чараларын төп бүлүче атамасы | ______ (Министрлык) | Җыелма реестр буенча | |
| | | | |
| Чара атамасы | ______ | БК буенча | |
| Субсидия атамасы | ______ | БК буенча | |
| | | Килешү номеры | |
| | | Килешү датасы | |
| Документ төре | ______ (беренчел – «0», тәгаенләнгән – «1», «2», «3», «...») | | |

| Субсидия бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Билгеләнеш | | | Ирешү вакыты (кк.аа.ееее.) | | Статус | Кире кагу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атамасы | код | тип | атамасы | ОКЕИ буенча | планлы | фактта | фараз | планлы | фактта (фараз) | | |

| | | | | код | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе: | | | | | | | | | | | |
| Хисап чорындагы контроль нокталар | х | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Алучының җитәкчесе (вэкаләтле зат) ____________ ____________ ____________

(вазифа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Башкаручы ____________ ____________ ____________

(вазифа) (фамилия, инициаллары) (телефон)

«__» _________ 20__ ел